| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«25» май 2026 ел** **№ 68**

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 6 февралендәге 22 номерлы «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатыннан норматив хокукый актны үзгәртү турында Теләче районы прокурорының 2026 елның 13 маендагы 02-01-14-2026/378-26-20920037 номерлы таләбен карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 6 февралендәге 22 номерлы «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» карарына (16.07.2024 № 89, 19.12.2024 № 163, 24.07.2025 № 97 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- күрсәтелгән карар белән расланган «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасына:

А) Программаның 1 «Программа паспорты» бүлегендә:

- «Программаның бурычлары» пунктының 5 пунктчасыннан «дәүләт һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

- «Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләре» пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның көтелгән соңгы нәтиҗәләре» | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәләре буенча 2028 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:<br>- Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының кадрлар сәясәтенә эчке контроль һәм коррупциягә каршы механизм керткән өлеше 100 процентка җитәчәк;<br>- аларның проектларын эшләү стадиясендә коррупциягә каршы экспертизага дучар ителгән закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар өлеше 100 процентка җитәчәк; |

| | |
|---|---|
| | - квалификациясен күтәрү узган муниципаль хезмәткәрләр өлеше ел саен кимендә 33 процент тәшкил итәчәк;<br>- коррупциягә каршы көрәш эшчәнлеген камилләштерү мәсьәләләре буенча методик материаллар белән 100 процент җирле үзидарә органнары тәэмин ителәчәк;<br>- коррупциягә каршы чаралар үткәрелгән муниципаль оешмалар хезмәткәрләре өлеше кимендә 50 процентка җитәчәк;<br>- гражданнарның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгатьлек дәрәҗәсе кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне "бер тәрәзә" принцибы буенча алу мөмкинлеге булган гражданнар өлеше, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәкләрендә, кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- үзләренең рәсми сайтларын мәгълүмат белән тәэмин итүче Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары өлеше, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының рәсми сайтларының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тутыруга Бердәм таләпләрне раслау турында" 2013 елның 04 апрелендәге 225 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән законнар һәм таләпләр нигезендә (алга таба - татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 04.04.2013 № 225 карары) кимендә 90 процент тәшкил итәчәк;<br>- дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны оештыру һәм уздыру өлкәсендәге эшчәнлекнең ачыклыгын тәэмин иткән Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары өлеше кимендә 100 процент тәшкил итә;<br>- коррупцияле ситуациягә эләккән эшмәкәрләр өлеше (Татарстан Республикасының социаль-икътисадый мониториг буенча комитеты үткәргән социологик тикшеренүләр мәгълүматлары буенча) 13,7 процenttан артык булмаячак |

Б) 2 Программаның чаралары бүлегендә:

- 5 пунктта «дәүләт һәм» сүзен төшереп калдырырга;
- 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.1 | Дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәткәндә Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт (муниципаль) хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары нигезләмәләренең үтәлешен тәэмин итү | ТМР БК территориаль үсеш бүлеге | 2024-2028 еллар | Гражданнарның, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны тәэмин итү, коррупцион хокук бозулар кылуга ярдәм итүче шартларны киметү | Чаралар оештыру характерында | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә» |

- 5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5.5 | Җирле үзидарә органнарында "ышаныч телефоннары" һәм "ышаныч әрҗәләре", Интернет-кабул итү каналлары, гражданнарга аларга мәгълүм коррупция фактлары, аларны башкаруга ярдәм итүче сәбәпләр һәм шартлар турында хәбәр итәргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүмат каналлары эшчәнлеген тәэмин итү | Район Советы Аппараты җитәкчесе, район Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе | 2024-2028 еллар | Коррупциягә каршы торуда иҗтимагый активлык дәрәҗәсен күтәрү, муниципаль органнарның гражданнар белән хезмәттәшлеген яхшырту | Чаралар оештыру характерында | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә | Финанслау лимитлары нигезендә» |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районы рәсми сайтында: http://tulachi.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин